РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

20.01.2025 № 9-п

Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 01 сентябрендәге 814-п номерлы карары белән расланган күпфатирлы йорттагы бинаны яңадан урнаштыруны һәм (яисә) яңадан планлаштыруны үткәрүне килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясе Торак кодексына һәм "Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында" Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында" 2023 елның 19 декабрендәге 608-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

**1.** Саба муниципаль районы Башкарма комитетының «Күпфатирлы йортта бинаны яңадан урнаштыруны һәм (яисә) яңадан планлаштыруны үткәрүне килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 01 сентябрендәге 814-п номерлы карары белән расланган күпфатирлы йорттагы бинаны яңадан урнаштыруны һәм (яисә) яңадан планлаштыруны үткәрүне килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1.** 1.5 нче пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Күпфатирлы йортта урынны үзгәртеп планлаштыру мондый бинаның чикләрен һәм (яисә) мәйданын үзгәртүдән һәм (яисә) яңа биналар булдырудан, шул исәптән әлеге Кодексның 40 статьясында каралган очракларда, һәм (яисә) аның эчке планлаштыруын үзгәртүдән (шул исәптән бинаның чикләрен һәм (яисә) мәйданын үзгәртмичә) гыйбарәт. Бинаны яңадан планлаштыру нәтиҗәсендә чиктәш биналарның чикләре һәм (яисә) мәйданы да үзгәртелергә мөмкин. Яңадан планлаштыру бинаның (урыннарның) чикләре һәм (яисә) мәйданы турында бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестры белешмәләренә үзгәрешләр кертү яисә төзелгән биналарны дәүләт кадастр исәбенә алу һәм төзелгән биналарга хокукны дәүләт теркәвенә алу кирәклегенә китерә."

**2.** Әлеге карар халыкка игълан ителгән мизгелдән үз көченә керә.

**3.** 5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының http://pravo.tatarstan.ru рәсми хокукый мәгълүмат порталында рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

Җитәкче М. Р. Ишниязов